СОВЕТ ВЕРХНЕОШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с..Верхняя Ошма, д.54 а, с. Верхняя Ошма,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422163

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ УШМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет ур., №54а нче йорт,ЮгарыУшма авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422163

тел.(факс): (85563) 2-32-36; e-mail: Voshm.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                                  Карар

№ 1-10                                                  от 29 июля 2016 года

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Мамадыш муниципаль районының Югары Ушма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Югары Ушма авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).
2. Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге «Югары Ушма авыл җирлеге башкарма комитетын төзү турында» № 1-4 карарының 2 пунктын үз көчен югалтты дип танырга.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Югары Ушма авыл җирлеге башлыгы М.Р.Хуҗәҗановка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Югары Ушма авыл
җирлеге башлыгы, җирлек Советы рәисе                    М.Р.Хуҗәҗанов